Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

31.10.2025 ел №2

"Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Яңа Илдерәк авылында үзара салым акчасы җыюны кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35статьясы ,Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР:

1. 2025 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча клуб бинасында билгеләргә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Иске Илдерәк, Үзәк урам, 7 йорт Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлегенең Яңа Илдерәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Яңа Илдерәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы вакытта юлларны карап тоту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, поселок юлларын ремонтлау, вак таш китерү, грунт һәм вак таш салу һәм тигезләү).
**2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләү һәм хезмәт күрсәтү), трактор тагылмасы һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу;
- урамнарны яктырту җайланмасы (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр китерү).
3) **җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**
су белән тәэмин итү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, Яңа Илдерәк торак пунктында тирән насосны ремонтлау һәм алыштыру (шартнамә буенча товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча әлеге карарны бастырып чыгарырга, авыл җирлеге яшәүчеләре күплэп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгарга, шулай ук Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге башлыгы: А.А. Морозов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
р 06-3759/13
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОИЛЬДЕРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1603004952 ОГРН 1061665003036